РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 82 2019 елның 20 декабре

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын хупларга һәм гавами тыңлауларда фикер алышуга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 гыйнварында 15 сәгатьтә Төзүчеләр пр., 12 адресы буенча Советлар йорты бинасының кече залында үткәрергә.

3. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм фикер алышуда гражданнарның катнашуын расларга (2 нче кушымта).

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Түбән Кама муниципаль районы Советы эшчәнлеген оештыру бүлеге белән берлектә:

4.1. әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) урнаштырырга;

4.2. әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында бастырырга;

4.3. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган («Ленинская правда» газетасында 2006 елның 4 ноябрендәге 218-219 номерларында басылып чыккан) Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан гавами тыңлауларда катнашу өчен кергән тәкъдимнәрне һәм гаризаларны кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказинага йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль
районы Советының
2019 елның 20 декабрендәге
82 номерлы карарына
1 нче кушымта

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
КАРАРЫ ПРОЕКТЫ

№ 20__ ел

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 нче статьялары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгына (А.Р. Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль
районы Советының
______ елның __ ______________
номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясы 1 өлешнең 8 пунктында «хокуклардан» сүзләреннән соң «аз санлы җирле халыклар һәм башкалар» сүзләрен өстәргә.

2. «Район составына керүче авыл җирлекләре территориясендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» 6.1 статьясы 1 өлешнең 12 пунктында «территорияләр, бирү» сүзләреннән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, бирү» сүзләрен өстәргә; «җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә кабул ителгән үзирекле төзелгән корылманы сүтү турында карары, үзирекле төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларына туры китерү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү карары (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү)» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. «Район Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат статусы» 27 статьясында:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфаларны үтәргә тиеш. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану, счетлар ачу һәм тоту тыюлуы турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ Федераль закон билгеләгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфалар үтәлмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса»;

б) 4.2. өлешендә «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яисә әлеге затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 4.3-1 өлешен өстәргә: «4.3-1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү игътибарга алырлык булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын район Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында, үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү белән район Советындагы, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфасыннан азат итү;

3) вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, район Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 4.3-2 өлеш өстәргә: «4.3-2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге статьяның 4.3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

4. «Яңа сайланган район Советы эшен оештыру» 28 статьясында 1 өлешнең икенче җөмләсендә «Район Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга

5. «Район Советы компетенциясе» 30 статьясында 1 өлешнең 3 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары законнары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары белән» сүзләренә алмаштырырга.

6. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 45 статьясында:

а) 5 өлешнең 5.2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 өлешнең 6.2 пунктында «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешнең 7.11 пунктына «хокуклар» сүзеннән соң «аз санлы җирле халыклар һәм башкалар» сүзләрен өстәргә.

7. «Районның контроль – хисап палатасы» 53 статьясында 4 өлешнең беренче җөмләсендә «ике» сүзен төшереп калдырырга.

8. «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керүе тәртибе» 76 статьясы 6 өлешендә «Район Башкарма комитеты җитәкчесен һәм аның урынбасарларын» сүзләрен «Район Башкарма комитеты җитәкчесен» сүзләренә алмаштырырга.

9. «Район бюджеты» 83 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә: «5. Районда бюджет процессын хокукый җайга салу Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, район Советы карары белән расланган районның бюджет – финанс сәясәте буенча нигезләмә һәм башка муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

10. 84-91 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

11. «Район Уставы проектын әзерләү, гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе» 92 статьясында 3 өлештә «Россия Федерациясе субъекты законнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

12. «Район Уставын кабул итү, гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе» 93 статьясында 4 өлештә «, гадәттәгечә» сүзләрен төшереп калдырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина

Түбән Кама муниципаль
районы Советының
2019 елның 20 декабрендәге
82 номерлы карарына
2 нче кушымта

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ
ТӘРТИБЕ

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектына тәкъдимнәр Түбән Кама муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12 (Советлар йорты бинасы) 204 кабинет яки факс буенча 41-70-00 кушып бирелә торган үрнәк нигезендә, төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада бирелә:

| т/с | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Түбән Кама ш., Төзүчеләр пр., 12адресы буенча шәхсән яисә почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулар» тамгасы белән), шулай ук 41-70-00 факсы буенча бирелә.

Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре совет эшчәнлеген оештыру бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә тапшырыла.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина